КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 10 март г.Казань № 122

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче; 2018 ел, 2 апрель, 200 нче; 2018 ел, 5 июнь, 425 нче; 2018 ел, 4 июль, 550 нче; 2018 ел, 8 декабрь, 1090 нчы; 2019 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2019 ел, 1 март, 148 нче; 2019 ел, 24 апрель, 339 нчы; 2019 ел, 26 апрель, 347 нче; 2019 ел, 29 апрель, 350 нче; 2019 ел, 28 август, 711 нче; 2019 ел, 16 сентябрь, 838 нче; 2019 ел, 26 декабрь, 1216 нчы; 2020 ел, 10 гыйнвар, 1 нче; 2020 ел, 24 февраль, 138 нче; 2020 ел, 10 июль, 571 нче; 2020 ел, 5 август, 657 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Үсемлекчелек, ачык грунт яшелчә культураларын, бәрәңге һәм орлык бәрәңгесен, техник киндерне һәм (яки) озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктның беренче абзацында «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

3 пунктның өченче абзацында «алучыларның» сүзе алдына «субсидияләр» сүзен өстәргә;

4 пунктның бишенче абзацында татар текстында «башка норматив хокукый актлар нигезендә» сүзләре үзгәрешсез кала;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үсемлекчелек өлкәсендә ярдәм күрсәтү өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = P \times S + P_{стр} \times S \times 1{,}2 + P_{фг} \times S \times 2{,}0,$$

монда:

P – субсидия алучының хисап финанс елының уңышы өчен авыл хуҗалыгы бөртекле, бөртекле-кузаклы, майлы (рапс һәм кытай борчагыннан тыш) һәм азык культураларының районлаштырылган сортлары һәм (яки) гибридлары утыртылган чәчү мәйданы, гектар;

S – субсидия алучының хисап финанс елының уңышы өчен авыл хуҗалыгы бөртекле, бөртекле-кузаклы, майлы (рапс һәм кытай борчагыннан тыш) һәм азык культураларының районлаштырылган сортлары һәм (яки) гибридлары утыртылган чәчү мәйданының 1 гектары өчен Министрлык боерыгы белән раслана һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә торган субсидия ставкасы, сум:

$$S = R \times \frac{K}{P_{РТ}},$$

монда:

R – тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

K – тиешле финанс елына җыелма бюджет язмасында каралган бюджет ассигнованиеләренең һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка бюджет акчасын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларының гомуми күләмендә әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча субсидиянең өлешен билгели торган һәм Министрлык боерыгы белән раслана торган коэффициент;

$P_{РТ}$ – барлык субсидия алучыларның хисап финанс елының уңышы өчен авыл хуҗалыгы бөртекле, бөртекле-кузаклы, майлы (рапс һәм кытай борчагыннан тыш) һәм азык культураларының районлаштырылган сортлары яки гибридлары утыртылган гомуми чәчү мәйданы, гектар;

$P_{стр}$ – агымдагы финанс елында авыл хуҗалыгы бөртекле, бөртекле-кузаклы, майлы (рапс һәм кытай борчагыннан тыш) һәм азык культураларының районлаштырылган сортлары һәм (яки) гибридлары чәчелгән һәм субсидия алучы тарафыннан иминиятләштерелгән, авыл хуҗалыгы культуралары уңышын иминиятләштерү шартнамәсе (шартнамәләре) белән расланган мәйдан, гектар;

$P_{фг}$ – хисап финанс елының уңышы өчен субсидия алучының авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр туфракларын фосфоритлаштыру һәм (яки) гипслаштыру эшләрен башкарганда проект-смета документларында чагылдырылган чәчү мәйданы, гектар.

Проект-смета документлары буенча авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр туфракларына фосфоритлар оны һәм (яки) гипс кертү һәм аларны фосфоритлаштыру һәм гипслаштыруны үткәрү күләмнәре үтәлмәгән очракта, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр туфракларын фосфоритлаштыру һәм (яки) гипслаштыруны үткәрү мәйданына субсидиянең исәп-хисабы башкарылмый.»;

6 пунктта:

беренче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

$6^{1}$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$6^{1}$. Орлык бәрәңгесен җитештерүне үстерү өлкәсендә ярдәм күрсәтү өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидиянең күләме ($W_{ск}$) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{ск} = (P_{ос} \times S_{ос}) + (P_{эс} \times S_{эс}),$$

монда:

$P_{ос}$ – агымдагы финанс елында субсидия алучының оригиналь бәрәңге орлыклары утыртылган мәйдан, гектар;

$S_{ос}$ – оригиналь бәрәңге орлыклары утыртылган мәйданның 1 гектарына 90 000 сум исәбеннән субсидия ставкасы;

$P_{эс}$ – агымдагы финанс елында субсидия алучының элиталы бәрәңге орлыклары утыртылган мәйдан, гектар;

$S_{эс}$ – бәрәңгенең элиталы орлыклары утыртылган мәйданның 1 гектарына 65 000 сум исәбеннән субсидия ставкасы.»;

7 пунктта:

беренче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

алтынчы абзацта «30 000» саннарын «25 000» саннарына алмаштырырга;

8 пунктның беренче абзацында «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

9 пунктта:

беренче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«проект-смета документациясе буенча авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр туфракларына фосфоритлар оны һәм (яки) гипс кертү һәм аларны фосфоритлаштыру һәм гипслаштыруны үткәрү күләмнәрен чагылдыра торган фосфоритлаштыру һәм (яки) гипслаштыру эшләрен үткәрү актлары күчермәләрен (булган очракта);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр туфрагын фосфоритлаштыруга һәм (яки) гипслаштыруга проект-смета документациясен (булган очракта).»;

10 пунктта:

беренче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

алтынчы абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

10.1 пунктта:

беренче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

11 пунктта:

беренче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

дүртенче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

12 пунктта:

бишенче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

алтынчы абзацта «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

җиденче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

унөченче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

ундүртенче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

13 пунктның «б» пунктчасында «алучы» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

$13^1$ пунктта:

икенче абзацта «1 августына» сүзләрен «31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «1 ноябренә» сүзләрен «31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «1 августына» сүзләрен «31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «1 ноябренә» сүзләрен «31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Министрлык әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма белешмәләр-исәп-хисаплар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына караган Казначылык департаментының территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

Субсидияләрне күчерү өчен Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелгән субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма белешмәләр-исәп-хисаплар нигез булып тора. Идарәләр үз шәхси счетына бюджет акчасын алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидияләрне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидияләр алучылар тарафыннан ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.»;

15 пунктта «бюджет законнары» сүзләре алдына «Россия Федерациясенең» сүзләрен өстәргә;

16 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга;

17 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга, «тикшерүне» сүзе алдына – «мәҗбүри» сүзен, «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

18 пунктта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бөртекле, бөртекле-кузаклы һәм (яки) майлы культуралар (рапстан һәм кытай борчагыннан тыш) җитештерүне үстерүне стимуллаштыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктта:

беренче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Әлеге Тәртип максатлары өчен «агымдагы ел уңышы өчен чәчүлекләр» төшенчәсе кулланыла – субсидия бирү елына кадәрге елда көзге авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләре биләгән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр мәйданы һәм агымдагы елда планлаштырыла торган һәм (яки) чәчелгән сабан бөртекле, бөртекле-кузаклы һәм майлы культуралар (рапс һәм кытай борчагыннан тыш) мәйданнары.»;

3 пунктта өченче һәм дүртенче абзацларны төшереп калдырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумнарда) түбәндәге формула буенча һәм түбәндәге шартларны исәпкә алып билгеләнә:

агротехнологик эшләр үткәргәндә субсидия алучы тарафыннан чәчү өчен Селекция казанышларының дәүләт реестрына кертелгән, Урта Идел рөхсәт итү төбәгендә кулланырга рөхсәт ителгән авыл хуҗалыгы культуралары, сортлар һәм (яки) гибридлар орлыкларын (алга таба – районлаштырылган орлыклар), шулай ук мондый орлыкларның сорт һәм чәчү сыйфатлары ГОСТ Р 325-2005 таләпләренә туры килү шартын үтәп куллану;

авыл хуҗалыгы культураларын җитештергәндә кулланыла торган минераль ашламаларны агымдагы ел уңышы өчен чәчүлекләрнең 1 гектарына гамәлдәге матдәгә күчереп исәпләгәндә кимендә 20 килограмм күләмендә сатып алу:

$$W = P_{зм} \times S_{зм} \times К_{м} \times К_{с},$$

монда:

$P_{зм}$ – субсидия алучының агымдагы ел уңышы өчен чәчүлекләре, гектар;

$S_{зм}$ – агымдагы ел уңышы өчен чәчүлекләрнең 1 гектарына түбәндәге формула буенча билгеләнә торган субсидия ставкасы, сум:

$$S_{зм} = \frac{R}{P_{змрт}},$$

монда:

R – тиешле финанс елына җыелма бюджет исемлегендә каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары күләме, сум;

$P_{змрт}$ – Татарстан Республикасы буенча барлык субсидия алучыларның агымдагы ел уңышы өчен чәчүлекләре, гектар;

$К_{м}$ – субсидия алучы тарафыннан әлеге пунктның икенче абзацында каралган шартлар үтәлмәгән очракта, ставкага 0,9 коэффициенты кулланыла;

$К_{с}$ – субсидия алучы тарафыннан әлеге пунктның өченче абзацында каралган шартлар үтәлмәгән очракта, ставкага 0,9 коэффициенты кулланыла.»;

6 пунктта:

беренче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

өченче абзацта «алучылар» сүзе алдына – «субсидия» сүзен, «законнарда» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнарда» сүзен «законнарында» сүзенә алмаштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы тарафыннан расланган һәм «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы белән килештерелгән, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча агымдагы ел уңышы өчен чәчүлекләр (шул исәптән районлаштырылган орлыклар чәчүлекләре) турында мәгълүмат, гектарларда;

субсидия алучы тарафыннан расланган һәм «Татарстан» агрохимия хезмәте үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе яки «Әлмәт» агрохимия хезмәте станциясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерелгән, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча хисап елының 1 сентябреннән агымдагы елның 1 сентябренә кадәр авыл хуҗалыгы культуралары җитештергәндә кулланыла торган минераль ашламаларны агымдагы ел уңышы өчен чәчүлекләрнең 1 гектарына гамәлдәге матдәгә исәпләп сатып алу турында мәгълүмат;»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хисап елының 1 сентябреннән агымдагы елның 1 сентябренә кадәр минераль ашламалар, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары, үсемлекләрне саклау чаралары, ягулык-майлау материаллары сатып алуны һәм (яки) куллануны раслый торган документлар (сату-сатып алу шартнамәләре, кабул итү-тапшыру актлары, товар йөкнамәләре, түләү документлары, минераль, органик һәм бактериаль ашламалар куллану турындагы актларның (420-АПК формасы) төп нөсхәләре һәм (яки) күчермәләре;»;

унөченче абзацта «алучы» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

7 пунктта:

бишенче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

алтынчы абзацта «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

җиденче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

ундүртенче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

8 пунктта:

«б» пунктчада «алучы» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

«д» пунктчада «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – килешүдә каралган субсидия бирү елының 31 декабре хәленә карата субсидия бирү елында бөртекле, бөртекле-кузаклы һәм (яки)

майлы культуралар (рапс һәм кытай борчагыннан тыш) җитештерү күләмнәрен үтәү, тоннада.»;

10 пунктта «15 октябренә» сүзләрен «31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Министрлык әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма белешмәләр-исәп-хисаплар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына караган Казначылык департаментының территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

Субсидияләрне күчерү өчен Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелгән субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма белешмәләр-исәп-хисаплар нигез булып тора. Идарәләр үз шәхси счетына бюджет акчасын алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидияләрне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидияләр алучылар тарафыннан ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.»;

12 пунктта «законнары» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә;

13 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзе алмаштырырга;

14 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзе алмаштырырга; «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

15 пунктта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

әлеге Тәртипкә кушымтада «15 октябрьгә кадәр бер тапкыр» сүзләрен «елга бер тапкыр» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөтле терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктның беренче абзацында:

«гыйнварында – июнендә» сүзләрен «гыйнварында – февралендә» сүзләренә алмаштырырга, «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

3 пунктта:

икенче абзацта «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

дүртенче абзацта «алучылардан» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

5 пунктта:

беренче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

алтынчы абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

җиденче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

6 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«К – Министрлык боерыгы белән раслана торган ставкага арттыру коэффициенты:

1,3 – хисап елында сыерларның уртача сөт продуктивлыгы республика буенча уртача продуктивлыктан югарырак, әмма 5 000 килограммнан ким булмаган субсидия алучылар өчен;

1,3 – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килә торган субсидия алучыларга сатылган һәм (яки) үз эшкәртүенә төяп җибәрелгән сөт күләме өчен;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөтле терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә торган субсидия күләме ($W_р$) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_р = W_я + W_ф,$$

монда:

$W_я$ – агымдагы елның гыйнвары өчен сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөте өчен субсидия алучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_я = V_я \times S_я,$$

монда:

$V_я$ – агымдагы елның гыйнварында субсидия алучы тарафыннан сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөтенең күләме;

$S_я$ – агымдагы елның гыйнварында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөтенең 1 килограммы өчен субсидиянең Министрлык боерыгы белән раслана һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә торган ставкасы:

$$S_я = \frac{\frac{W}{2}}{V_я},$$

монда:

W – тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган ассигнованиеләр күләме;

$W_ф$ – агымдагы елның февралендә сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөте өчен субсидия алучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә торган субсидия күләме:

$$W_ф = V_ф \times S_ф,$$

монда:

$V_ф$ – агымдагы елның февралендә субсидия алучы тарафыннан сатылган һәм (яки) төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөтенең күләме;

$S_ф$ – агымдагы елның февралендә сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөтенең 1 килограммы өчен субсидиянең Министрлык боерыгы белән раслана һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә торган ставкасы:

$$S_ф = \frac{\frac{W}{2}}{V_ф}.»;$$

8 пунктта:

тугызынчы абзацта «гыйнварында – июнендә» сүзләрен «гыйнварында – февралендә» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«агымдагы финанс елының гыйнварында – февралендә субсидия алучы тарафыннан сату һәм (яки) төяп җибәрү фактын раслый торган товар йөкнамәсе һәм ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып рәсмиләштерелгән ветеринария документлары күчермәләрен;»;

9 пунктта:

бишенче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

алтынчы абзацта «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

җиденче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);»;

ундүртенче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Министрлык әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма белешмәләр-исәп-хисаплар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына караган Казначылык департаментының территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

Субсидияләрне күчерү өчен Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелгән субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма белешмәләр-исәп-хисаплар нигез булып тора. Идарәләр үз шәхси счетына бюджет акчасын алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидияләрне

Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидияләр алучылар тарафыннан ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.»;

13 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә;

14 пунктта «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә;

15 пунктта:

«законнарда» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнарда» сүзен «законнарында» сүзенә алмаштырырга, «алучылар» сүзеннән соң «субсидия» сүзен өстәргә;

16 пунктта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин